МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.12.2018 г.Казань № 1151

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 28 гыйнварендә теркәлде, № 5411

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесе турында

Социаль һәм хезмәт өлкәсендә эшләүче яшьләрнең иң яхшы остазларын бүләкләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карарының 4.17 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесен гамәлгә куярга.

2. Расларга:

әлеге боерыкның 1 нче кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесе турында нигезләмә;

әлеге боерыкның 2 нче кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесенә тасвирлама.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 28.12.2018 1151 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство
аерымлылык билгесе турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесе (алга таба - Аерымлылык билгесе) ведомство бүләге булып тора, аның белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының югары квалификацияле дәүләт граждан хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы буйсынуындагы учреждениеләрнең хезмәткәрләре (алга таба – социаль-хезмәт өлкәсе хезмәткәрләре, Министрлык, учреждениеләр) исәбендәге яшьләрнең иң яхшы остазлары бүләкләнә.

2. Остазлык эшчәнлеге дигәндә әлеге Нигезләмәдә түбәндәгеләр аңлашыла:

- яшь белгечләргә аларның профессиональ өлгереп җитлегүендә профессиональ белемнәрне, күнекмәләрне һәм осталыкларга уңышлы ия булуга булышлык күрсәтү;

- яшь белгечләргә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартларына профессиональ һәм вазыйфаи яраклашуда, шулай ук вазыйфаи бурычларны үтәгәндә барлыкка килә торган профессиональ авырлыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү;

- яшь белгечләрне индивидуаль эшләүнең һәм коллективта эшләүнең нәтиҗәле формаларына һәм методларына өйрәтү, вазыйфаи бурычларны мөстәкыйль һәм сыйфатлы башкару, үз һөнәри дәрәҗәсен арттыру сәләтен үстерү.

3. Аерымлылык билгесе белән социаль-хезмәт өлкәсе хезмәткәрләре бүләкләнә, бер үк вакытта түбәндәге таләпләргә җавап биргәндә:

а) социаль-хезмәт өлкәсендәге өзлексез эш стажы биш елдан аз түгел;

б) квалификация дәрәҗәсенең (белем алу, квалификацияне үстерү турында документларның), профессиональ казанышларның (профессиональ эшчәнлек, профессиональ осталык конкурсларында җиңү өчен бүләкләр һәм бүләкләүләр һ.б.) булуы; дисциплинар түләттерүләрнең булмавы;

в) кимендә өч ел дәвамында остазлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру (актив һәм намуслы остазлык эшчәнлеге өчен бүләкләр һәм бүләкләүләр; остазлык эшчәнлегендә уникаль тәҗрибәләр (программалар) булуы; остазга беркетелгән хезмәткәрләрнең профессиональ казанышлары (квалификациянең раслануы, бүләкләр һәм бүләкләүләр), аларның карьерада үсүе).

4. Кандидатны Аерымлылык билгесе белән бүләкләүгә күрсәтү учреждение хезмәткәрләренең гомуми җыелышында (конференциясендә) карала һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5. Аерымлылык билгесе белән бүләкләү Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасарларының, эшләр белән идарә итүченең, Министрлыктагы структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һәм учреждениеләр җитәкчеләренең Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш

белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – Министр) исеменә үтенеч язуы нигезендә Министрлык боерыгы белән башкарыла.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән Министрлык вазыйфаи затларының үтенеч язуында түбәндәгеләр булырга тиеш:

бүләкләүгә тәкъдим ителүчегә аның конкрет казанышларын күрсәтеп сыйфатлама;

бүләкләүгә тәкъдим ителүченең эше турында мәгълүмат һәм белешмәләр.

Учреждение җитәкчесенең Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турындагы үтенеч язуына әлеге Нигезләмә кушымтасына туры китерелгән форма буенча Министрлыкның ведомство бүләге белән бүләкләүгә күрсәтмә (алга таба – Күрсәтмә) теркәлә.

Күрсәтмә төгәл шрифт белән, буяуларсыз һәм хаталарсыз тутырыла.

Бүләкләүгә тәкъдим ителүченең (алга таба – кандидат) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) аның паспорт белешмәләренә туры китереп күрсәтелә.

Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турында үтенеч язуы Министр исеменә кәгазьдәге документ формасында, шулай ук вәкаләтле вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла һәм Министрлыкның эш башкару бүлегендә мәҗбүри теркәлергә тиешле:

- шәхсән кабул иткәндә яисә үтенеч язуы һәм документлар почта аша килгәндә – үтенеч язуы һәм документлар килгән көнне;

- үтенеч язуы, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм документлар Министрлыкка килгән көнне яисә, үтенеч язуы һәм документлар Министрлыкның эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы көндә. Үтенеч язуы һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта аны теркәү Министрлыкның ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә гамәлгә ашырыла.

6. Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турында үтенеч белән чыккан зат күрсәтмәдә (үтенеч язуында) күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге өчен шәхсән җаваплы була.

7. Аерымлылык билгесе белән бүләкләүгә бәйле мәсьәләләрне беренчел карау Министрлык боерыгы белән оештырылган, Министрлыкның Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турында документларны карау буенча комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла, ул әлеге билге белән бүләкләү турында материалларны бәяли, кандидатның әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе (туры килмәве) турында бәяләмә бирә.

Бүләкләү турында документларны караганда Комиссия, бүләкләүгә тәкъдим ителгән документлардагы белешмәләрнең дөреслеген раслау максатларында, билгеләнгән тәртиптә үтенеч белдерүче учреждениегә, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм бүтән оешмаларга гарызнамәләр җибәрергә хокуклы.

8. Комиссия тарафыннан Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турындагы документларны карау срогы аларны Министрлыкта теркәгән көннән башлап 10 эш көненнән артыграк була алмый.

Комиссия, Аерымлылык билгесе белән бүләкләү өчен тапшырылган

документларда төгәл булмаган мәгълүмат булуын, Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турындагы документлар составында зарури тапшырылырга тиешле документларның әлеге Нигезләмнең 5 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килмәвен ачыклаган очракта, бүләкләү өчен тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве турында карар кабул итә һәм бу хакта үтенечнең инициаторы булган затка гариза Министрлыкта теркәлгән көннән башлап 10 эш көне узганчы хәбәр итә.

Кандидатның вафат булуы турында мәгълүмат килгән очракта бүләкләү турында үтенеч язуын алга таба карау туктатыла.

9. Кандидатны Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турындагы документларны карау көненнән башлап өч эш көне узганчы Комиссия тарафыннан, әлеге Нигезләмәнең 8 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, кандидатның Аерымлылык билгеле белән бүләкләү таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында язмача бәяләмә рәсмиләштерелә һәм Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә тапшырыла һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итү турында киңәшләр бирелә:

а) кандидатны аерымлылык билгесе белән бүләкләргә;

б) кандидатны аерымлылык билгесе белән бүләкләүдән баш тартырга.

10. Кандидатны Аерымлылык билгесе белән бүләкләүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен кандидатның әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве нигез булып тора.

Кандидатны Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турында яки кандидатны Аерымлылык билгесе белән бүләкләүдән баш тарту турында боерык проекты Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан Министрга Комиссия бәяләмәсен алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта тапшырыла.

Министр кандидатны Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турында карар кабул иткән очракта, Аерымлылык билгесен тапшыру бүләкләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көне эчендә тантаналы шартларда Министр тарафыннан яки аның йөкләмәсе буенча Министрлыкның башка вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла.

Министр кандидатны Аерымлылык билгесе белән бүләкләүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта, бу хактагы хәбәр карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта кандидатны Аерымлылык билгесе белән бүләкләү турында үтенеч язуының инициаторы булган затка кабул ителгән карарны һәм аны кабул итү сәбәпләрен күрсәтеп җибәрелә.

11. Аерымлылык билгесе белән бүләкләү кабатлап башкарылмый һәм, югалткан очракта, аның дубликаты бирелми.

12. Бүләкләнүче шәхси, әхлакый сыйфатларына белдерелә торган таләпләргә туры килмәүче гамәлләрне башкарган өчен, суд карары яки Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге күрсәтмәсе буенча Министр карары нигезендә Аерымлылык билгесеннән мәхрүм ителергә мөмкин. Аерымлылык билгесеннән мәхрүм ителгән очракта Аерымлылык билгесеннән мәхрүм итү турында Министрлык боерыгы чыгарыла. Бу очракта Аерымлылык билгесе Министрлыкка кайтарып бирелергә тиеш.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесе турында нигезләмәгә кушымта

РӘВЕШЕ

## Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесе белән бүләкләүгә күрсәтмә

______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________________________
(эш урыны һәм биләгән вазыйфасы)

______________________________________________

Туу елы______________________________________

Туу урыны ___________________________________

Белеме ______________________________________

Тәмамлаган (кайчан, нәрсә)___________________

Белеме буенча белгечлеге ____________________

Нинди бүләкләр белән бүләкләнгән_____________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

ЭШЕ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАР

__ ____ ел. башлап __ ____ ел. кадәр. Вазыйфасы, эш урыны, учреждениенең, оешманың урнашкан урыны

Икенче ягы

Сыйфатлама

(кемгә)_______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме - тулысынча)

______________________________________________
(биләнә торган вазыйфа)

______________________________________________
*(сыйфатлама тексты)*

______________________________________кандидатурасы

______________________________________________
(оешманың аталышы)

______________ хезмәткәрләрнең җылышында (конференциясендә) тәкъдим ителде.

______________________________________________
(фикерләшү датасы, беркетмә №)

Оешма җитәкчесе

______________________
(имза)

______________________
(фамилия һәм инициаллар)

Хезмәткәрләр җыелышының (конференциясенең) рәисе

______________________
(имза)

______________________
(фамилия һәм инициаллар)

М.У. «__» ___________ ел.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 28.12.2018 1151 номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство
аерымлылык билгесенә тасвирлама

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мактаулы остаз» ведомство аерымлылык билгесе А4 зурлыгындагы диплом-плакеткадан гыйбарәт.

Плакетка 305*230 мм зурлыгындагы, 15 мм калынлыгындагы, тыгызланган агачтан әзерләнгән агач плитәдән гыйбарәт. Агач нигезендә периметры буенча фаскалар бар, төсе куе коңгырт. Арткы ягында горизонталь яки вертикаль торышында элеп кую өчен каты тишекләре бар. Плитәгә 280*200 мм зурлыгындагы турыпочмак формасында алтын төсендәге анод белән оксидлаштырылган тонык металл пластина беркетелә, аңа турыдан-туры тулы төсле нәшер ярдәмендә югары температура йогынтысында сурәтләү методы белән сурәт һәм текст төшерелә.

Пластинаның өске өлешендә сурәт урнашкан: салат, яшел һәм кызыл төсләрдәге салават күпере астында кеше рәвешендә соры төстәге рәсем һәм рәсем астында дүрт юл - «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ» соры шрифт белән язылган сүзләр.

Сурәт астында түбәндәгечә язылган: «Мактаулы остаз».

Аскы өлешендә бүләкләнүченең шәхси белешмәләре язылган юл: фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта) һәм вазыйфасы.

Плакетканың уң як өлешендә сул юлдан аста ике юлга кара шрифт белән «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» дип язылган, уң якта – Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының инициаллары һәм фамилиясе.

Аска таба кара төстәге «М.У.» хәрефләре язылган, алар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының герб мөһере урыны дигәнне аңлата, ә алар астында уң як почмакта - кара шрифтлар белән «Казан» язуы.